Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №Ш-11**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 16 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 5 августындагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүдән азат итү шартлары турында” LIV-5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р, 2020 елның 6 августындагы 1497-р номерлы Күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 5 августындагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүдән азат итү шартлары турында” LIV-5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Карарның беренче абзацында “820-р” не “821-р” дип укырга.

1.2 1 пунктта:

1.1.1 “а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар – кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручыларның коммерциягә карамаган оешмалар реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы оешмалар мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде эш көне эчендә Россия икътисадының яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә вазгыятьнең начараюы шартларында иң күп дәрәҗәдә зыян күрүче тармаклар Исемлеге (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә вазгыятьнең начараю шартларында аеруча зыян күргән

Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында” 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган Исемлек) буенча бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып баручы оешмаларга 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүдән азат итү һәм 2020 елның 1 июленнән 2020 елның 1 октябренә кадәр аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору турында өстәмә килешүләр төзү.

Арендатор икътисади эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә, алар турында 2020 елның 1 апреленә торыш буенча мәгълүмат юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында яисә индивидуаль эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрында бар.

Өстәмә килешүләр Татарстан Республикасы казнасына (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче дәүләт мөлкәтен арендага бирүне күздә тота торган аренда шартнамәләренә, аны икътисади эшчәнлекнең күрсәтелгән төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен куллану максатларында һәм күрсәтелгән төрен (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәтне кулллануны раслаучы документлар булганда, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага торышы буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган арендаторлар белән аренда килешүләренә төзелә.”;

1.1.2 “б” пунктчасында “кече һәм урта эшкуарлык субъектлары” сүзләреннән соң “социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар” сүзләрен өстәргә;

1.3 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.Әлеге күрсәтмәнең (боерыкның) 1 пунктының “а” пунктчасында күрсәтелгән арендаторлар белән өстәмә килешүләр түбәндәге шартларда төзелә:

аренда түләве буенча бурыч арендаторлар тарафыннан тәкъдим ителгән срокта 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап түләнә, айга бер тапкырдан да ешрак түләнергә тиеш түгел, тигез түләүләр белән, аларның күләме аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмый;

кичектереп торуга бәйле рәвештә штрафлар, чит акчалардан файдаланган өчен процентлар яисә арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле рәвештә җаваплылыкның башка чаралары кулланылмый (шул исәптән, мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда);

кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

аренда шартнамәсе вакытыннан алда өзелгәндә аренда түләве буенча бурыч бер түләүдә түләнә.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Г. Әхмәтҗанова